ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 426-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Тыгин тарафыннан кертелгән «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 426-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 2000-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.В. Тыгин тарафыннан кертелә

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7–8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Республика башкарма хакимиятенең региональ дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле органын (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы) билгеләү;»;

2) 6 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимиятенең бүтән органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта «, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында салкын судан, җылы судан файдалану, агып төшкән суны җибәрү, электр энергиясен куллану нормативларын» сүзләрен «(шул исәптән торак фонды объектларыннан каты көнкүреш калдыклары туплану нормативларын), күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслардан файдалану нормативларын» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$). муниципаль берәмлектә Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 19 өлешендә күрсәтелгән иҗтимагый оешмалар, коммерциягә карамаган башка оешмалар төзүгә һәм аларның эшчәнлегенә ярдәм итәләр;»;

б) 2 өлештә «8 өлешендә» сүзләрен «19 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 72-ТРЗ номерлы Закон) гамәлдә булуына анализ ясау нәтиҗәләре буенча аның аерым нигезләмәләрен, терминологияне һәм сылтама нормаларны төгәлләштерү максатларында эшләнде.

Закон проектында Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы (19 өлеш) һәм 165 статьясы (1 өлеш) нигезләмәләре нигезендә урыннар милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында (72-ТРЗ номерлы Законның 7 статьясындагы 1 өлеше ) җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган чаралар исемлеген, аңа иҗтимагый торак контроле субъектларын (иҗтимагый берләшмәләр, коммерциягә карамаган башка оешмалар) төзүгә ярдәм итү чарасын өстәп, киңәйтү тәкъдим ителә. Берүк вакытта 72-ТРЗ номерлы Законның 7 статьясындагы 2 өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы нормасына сылтаманы төгәлләштерү күздә тотыла.

72-ТРЗ номерлы Законның 4, 6 һәм 10 статьяларындагы үзгәрешләр әлеге статьяларда кулланыла торган терминологияне «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, шулай ук торак законнарының актуаль формулировкаларына (6 статьяның 2 пункты) туры китерүгә юнәлдерелгән.

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итми.